**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 мартындагы 895 номерлы карары**

**«1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасы буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьялары, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 8 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 августындагы 3686 номерлы «“1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү” линия объекты территориясен ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 маендагы 2244 номерлы карары белән расланган «1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен плнлаштыру проекты нигезендә **карар бирәм**:

1. «1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен ызанлау проектын әлеге карар кушымтасы нигезендә расларга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә:

2.1. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә кую өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат бирергә;

2.3. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

2.3.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмалар өчен аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

2.3.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

2.3.3. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 749-П номерлы белән расланган Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен һәм сак предметын үтәргә.

3. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

4. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 26 мартындагы
895 номерлы карары белән
расланды

**«1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү»**
**линия объекты территориясен ызанлау проекты**

«1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен ызанлау проектына түбәндәгеләр керә:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген, 16:50:012303:2 кадастр номерлы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген, 16:50:000000:34 кадастр номерлы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген теркәп, территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап, 2 нче этап).

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, 16:50:012303:2 кадастр номерлы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, 16:50:000000:34 кадастр номерлы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

«1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен ызанлау проекты Татарстан Республикасы Казан

шәһәренең Вахитов районында яңгыр канализациясе челтәрләрен урнаштыру өчен җир кишәрлеген ясау максатыннан эшләнде.

Ызанлау проекты территориясенең мәйданы – 17323 кв.м.

Төзелеш һәм файдалану чорына «1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объектын план буенча урнаштыру полосасы киңлеге һәм зонасы чикләре Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 маендагы 2244 номерлы карары белән расланган «1000 мм диаметрлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты белән билгеләнде.

Территорияне ызанлауның әлеге проекты белән ике этапта җир кишәрлекләре ясау каралган.

1 нче этапта Татарстан Республикасы милкендәге 16:50:012302:1 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклаган хәлдә бүлү юлы белән :ЗУ1 шартлы билгеләнешле бер җир кишәрлеге ясау күздә тотыла.

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә :ЗУ1 шартлы билгеләнешле ясала торган җир кишәрлегенә 16:50:012302:1 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлегенең «Спорт корылмалары өчен» рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү зарур.

Кадастр эшләрен башкарганнан соң, :ЗУ1 шартлы билгеләнешле ясала торган җир кишәрлегенә «Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (код 3.1.1), Урам-юл челтәре (код 12.0.1)» рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләргә кирәк.

2 нче этапта формалаштырыла торган җир кишәрлеген 1 нче этап кысаларында формалаштырылган :ЗУ1 шартлы билгеләнешле җир кишәрлегенә муниципаль милек хокукын теркәгәннән соң ясарга мөмкин.

2 нче этап 1 нче этап кысаларында формалаштырылган :ЗУ1 шартлы билгеләнешле беренчел җир кишәрлеге белән дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы аша :ЗУ2 шартлы билгеләнешле бер җир кишәрлеге ясауны күздә тота.

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә :ЗУ2 шартлы билгеләнешле ясала торган җир кишәрлегенә :ЗУ1 шартлы билгеләнешле беренчел җир кишәрлегенең «Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (код 3.1.1), Урам-юл челтәре (код 12.0.1)» рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләргә кирәк.

1 нче һәм 2 нче этапларда ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге һәм аларның мәйданнары, ясау ысуллары, җирләрнең категориясе һәм рөхсәт ителгән файдалану төрләре турында белешмәләр 1 таблицада китерелгән.

ЗУ2 шартлы билгеләнешле җир кишәрлеге линия объектын урнаштыру

өчен билгеләнгән җир кишәрлеге булып тора һәм берничә территориаль зона чикләрендә урнашкан.

2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында»гы федераль закон һәм Россия Федерациясенең Җир кодексы нигезләмәләре буенча линия объектын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлеген берничә территориаль зонада урнаштыру мөмкин.

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясында билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата таләпләр үтәлгән.

16:50:012303:2, 16:50:000000:34 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә ачык сервитут чикләрен билгеләү линия объектын урнаштыру һәм төзү өчен кирәк һәм Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә ачык сервитут суүткәргеч челтәрләре объектларын, су чыгару челтәрләрен төзү, реконструкцияләү, алардан файдалану, капиталь ремонтлау максатыннан җир кишәрлекләреннән һәм (яисә) җирләрдән файдалану өчен билгеләнә.

Ачык сервитут шартларында линия объекты урнаштырылырга мөмкин булган җир кишәрлекләре исемлеге һәм алар турында белешмәләр 2 таблицада китерелгән.

1 таблица

| **Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Ясала торган җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Җир кишәрлеген ясау ысулы** | **Ясала торган җир кишәрлегенә карата билгеләнә торган җирләр категориясе** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Этап** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 16:50:012302:1 | 693 | Татарстан Республикасы милкендәге 16:50:012302:1 кадастр номерлы җир кишәрлеген үзгәргән чикләрдә саклаган хәлдә бүлү | Торак пунктлардагы җирләр | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (код 3.1.1), Уличны-юл челтәре (код 12.0.1) | 1 |
| :ЗУ2 | :ЗУ1 | 2306 | 1 нче этап кысаларында формалаштырылган :ЗУ1 шартлы номерлы беренчел җир кишәрлеге белән дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү | Торак пунктлардагы җирләр | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (код 3.1.1), Уличны-юл челтәре (код 12.0.1) | 2 |

2 таблица

| **Сервитут, ачык сервитут шартларында линия объекты урнаштырылырга мөмкин җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Сервитут мәйданы, кв.м** | **Җир кишәрлегенең урнашу урыны (адресы) турында мәгълүмат** |
|---|---|---|---|
| 16:50:012303:2 | Күпфатирлы йорт | 2 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Вахитов районы, Девятаев урамы, 7 йорт |
| 16:50:000000:34 | Тимер юл транспорты | 156 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре территориясендә тимер юл полосасы чикләре зонасындагы кишәрлек |

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 36 статьясы нигезләмәләре буенча линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән ясала торган җир кишәрлекләренә шәһәр төзелеше регламенты йогынтысы кагылмый.

:ЗУ2 шартлы билгеләнешле ясала торган җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда, Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 749-П номерлы әмере белән расланган Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен һәм сак предметын үтәү зарур.


Ясала торган җир кишәрлекләре график өлештә күрсәтелгән.

Ясала торган җир кишәрлекләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.


# II. Территорияне ызанлау сызымы
# (1 нче этап)




**Условные обозначения:**

- Красные линии существующие
- Границы территории проекта межевания
- Границы кадастровых кварталов
- Границы территориальных зон
- Границы учтенных земельных участков/объектов капитального строительства
- Границы исходного земельного участка
- 16:50-6.5739 Реестровые (учетные) номера ЗОУИТ границ АТД, внесенных в ЕГРН
- 16:50:100419:1159 Кадастровые номера учтенных земельных участков/объектов капитального строительства
- 16:50:100419 Кадастровые номера кадастровых квраталов
- 16:50-7.11.98 Реестровые номера территориальных зон
- н1 Обозначение и номер характерных точек границ образуемого земельного участка
- 16:50:012302:1 Кадастровый номер исходного земельного участка, сохраняемого в измененных границах
- Границы ЗОУИТ, внесенных в ЕГРН (учтенных)
- н1 Обозначение и номер характерных точек границ территории проекта межевания
- :ЗУ1 Обозначение образуемого земельного участка
- Границы образуемого земельного участка
- Границы сферы действия планируемых публичных сервитутов
- Границы земельных участков на которых линейный объект может быть размещен на условиях публичного сервитута
- 16:50:000000:34, 16:50:012303:2 Кадастровые номера земельных участков на которых линейный объект может быть размещен на условиях публичного сервитута
- н1 Обозначение и номер характерных точек границ планируемых публичных сервитутов

# Территорияне ызанлау сызымы
# (2 нче этап)




**Условные обозначения:**

- Красные линии существующие
- Границы территории проекта межевания
- Границы кадастровых кварталов
- Границы территориальных зон
- Границы учтенных земельных участков/объектов капитального строительства
- Границы исходного земельного участка
- 16:50-6.5739 Реестровые (учетные) номера ЗОУИТ границ АТД, внесенных в ЕГРН
- 16:50:100419:1159 Кадастровые номера учтенных земельных участков/объектов капитального строительства
- 16:50:100419 Кадастровые номера кадастровых кваратлов
- 16:50-7.11.98 Реестровые номера территориальных зон
- н1 Обозначение и номер характерных точек границ образуемого земельного участка
- :ЗУ1 Обозначение исходного земельного участка
- Границы ЗОУИТ, внесенных в ЕГРН (учтенных)
- н1 Обозначение и номер характерных точек границ территории проекта межевания
- :ЗУ2 Обозначение образуемого земельного участка
- Границы образуемого земельного участка
- Границы сферы действия планируемых публичных сервитутов
- Границы земельных участков на которых линейный объект может быть размещен на условиях публичного сервитута
- 16:50:000000:34, 16:50:012303:2 Кадастровые номера земельных участков на которых линейный объект может быть размещен на условиях публичного сервитута
- н1 Обозначение и номер характерных точек границ планируемых публичных сервитутов